ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

площадь Советская, д.12, г.Арск, 422000

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Совет мәйданы, 12 нче йорт, Арча шәһәре, 422000

Тел. (84366)3-00-44, факс (84366)3-11-44. E-mail: archa@tatar.ru. www.arsk.tatarstan.ru

**КАРАР**

**«13» апрель 2022 ел** **№ 442**

**«2019-2022 елларга Татарстан Республикасы Арча муниципаль районында физик культура һәм спортны үстерү программасын раслау турында» Арча муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 26 ноябрендәге 1039 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында (28.04.2020 №322, 28.09.2020 №735, 06.04.2021 №239, 22.12.2021 №2263, 01.04.2022 № 243 үзгәрешләр белән)**

Арча муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. «2019-2022 елларга Татарстан Республикасы Арча муниципаль районында физик культура һәм спортны үстерү программасын раслау турында» Арча муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 26 ноябрендәге 1039 номерлы карарына(28.04.2020 №322, 28.09.2020 №735, 06.04.2021 №239, 22.12.2021 №2263, 01.04.2022 №243 үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. «2019-2022 елларга Татарстан Республикасы Арча муниципаль районында физик культура һәм спортны үстерү программасын раслау турында» Арча муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 26 ноябрендәге 1039 номерлы карары белән расланган «2019-2024 елларга Татарстан Республикасы Арча муниципаль районында физик культура һәм спортны үстерү программасы»н кушымта нигезендә яңа редакциядә бәян итәргә.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Арча муниципаль районының рәсми сайтында (http://arsk.tatarstan.ru) (http://arsk.tatarstan.ru)урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Арча муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасарына йөкләргә.

Башкарма комитет җитәкчесе Р.М.Гатиятов

Арча муниципаль районы
Башкарма комитетының
13.04.2023 ел, № 442
карарына кушымта

**2020–2024 елларга Татарстан Республикасы Арча муниципаль районында физик культура һәм спортны үстерү**
**МУНИЦИПАЛЬ ПРОГРАММАСЫ**

**Программаның паспорты**

| | |
|---|---|
| Муниципаль программаның исеме | "2020 - 2024 елларга Татарстан Республикасы Арча муниципаль районында физик культура һәм спортны үстерү" муниципаль программасы (алга таба-Программа) |
| Муниципаль программаны эшләү өчен нигезләр | Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2009 елның 7 августындагы 1101-р күрсәтмәсе белән расланган 2020 елга кадәр Россия Федерациясендә физик культураны һәм спортны үстерү Стратегиясе; "Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында" 1995 елның 24 ноябрендәге 181-ФЗ номерлы Федераль закон (24.07.2009 редакциядә) (РФ ДД ФС тарафыннан 20.07.1995 елда кабул ителгән); "Физик культура һәм спорт турында" 2008 елның 8 октябрендәге 99-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы (29.06.2010 редакциядә); "2011-2015 елларга Россия Федерациясе гражданнарын патриотик тәрбияләү буенча дәүләт программасы турында" 2010 елның 5 октябрендәге 795 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары; Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 11 февралендәге 90 номерлы "2013-2017 елларга балалар мәнфәгатьләрендәге чараларның республика стратегиясе турында" карары; "2019-2021 елларга Татарстан Республикасында физик культураны һәм спортны үстерү" дәүләт программасын раслау турында" Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 елның 5 мартындагы 159 номерлы карары |
| Муниципаль программаның заказчысы | Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге |
| Муниципаль программаның төп максаты | 1.Физик культура һәм спорт белән шөгыльләнүдә халыкның агымдагы ихтыяҗларын канәгатьләндерү һәм яңа ихтыяҗларын формалаштыру.<br>2.Яшьләрне физкультура-спорт эшчәнлегенә җәлеп итү хисабына халыкның авыру дәрәҗәсен һәм криминоген хәлне киметү.<br>3. Сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру.<br>4. Арча муниципаль районының барлык халкы тарафыннан сәламәт яшәү рәвеше алып бару өчен шартлар тудыру |
| Муниципаль программаның төп бурычлары | 1. Халыкта физик культура һәм спорт белән шөгыльләнүгә, сәламәт яшәү рәвеше күнекмәләренә карата тотрыклы кызыксыну |

| | |
|---|---|
| | формалаштыру;<br>2. Спортчыларны әзерләүнең нәтиҗәле системасын булдыру, шәһәрнең спорт корылмаларының матди-техник базасын ныгыту һәм үстерү;<br>3. Арча муниципаль районы һәм Татарстан Республикасы спорт командалары резервын һәм югары класслы спортчыларны әзерләү өчен оптималь шартлар тудыру;<br>4. Халыкның төрле категория һәм төркемнәренә физик тәрбия бирү системасын модернизацияләү;<br>5. Арча районында яшәүчеләр өчен физик культура һәм спорт өлкәсендә һәркем файдалана алырлык инфраструктура булдыру һәм үстерү;<br>6. Балалар һәм яшьләр өчен спортның төрле төрләре буенча календарь укыту-спорт чараларын үткәрү өчен шартлар тудыру;<br>7. Яшәү урыны буенча спорт-сәламәтләндерү чараларын оештыру һәм уздыру өчен шартлар тәэмин итү;<br>8. Гомумшәһәр массакүләм спорт чараларын оештыру һәм уздыру өчен шартлар тәэмин итү;<br>9. Шәһәр халкының төрле категорияләре өчен массакүләм спорт-сәламәтләндерү чараларын оештыру һәм уздыру өчен шартлар тудыру;<br>10. Сәламәт яшәү рәвешенең мөһим өлеше буларак физик культура һәм спортны пропагандалауны камилләштерү;<br>11. Яшьләр инфраструктурасын үстерү һәм тотрыклы эшләтү;<br>12. Физкультура-спорт эшчәнлеген оештыру-идарә итү, кадрлар, фәнни-методик тәэмин итүне үстерү |
| Программаның төп чараларын башкаручылар | Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге<br>Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитетының "Мәгариф идарәсе" МУ<br>Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитетының "Мәдәният идарәсе" МУ<br>Арча муниципаль районының социаль яклау идарәсе |
| Программаны гамәлгә ашыру сроклары һәм этаплары | 2020-2024 еллар |
| Муниципаль программаның максатларына ирешү индикаторлары | Программаны гамәлгә ашыру нәтиҗәсендә 2024 ел ахырына планлаштырыла:<br>- район халкының физик культура һәм спорт белән даими шөгыльләнүче өлешен 66,4 процентка җиткерү;<br>- халыкка түләүле физкультура-спорт хезмәтләренең күләмен арттыру һәм сыйфатын күтәрү;<br>-гражданнарның авырулар санын киметү, хәрби хезмәткә чакырылуга кадәрге һәм хәрби хезмәткә чакырылучы үсмерләрнең физик әзерлеген яхшырту;<br>- республика, бөтенроссия һәм халыкара ярышларда чыгыш ясаучы Арча муниципаль районы спортчылары санын арттыру;<br>-физик культура һәм спорт чаралары ярдәмендә мөмкинлекләре чикләнгән кешеләрне физик тернәкләндерү һәм социаль адаптацияләү ролен арттыру |

<table>
<tr>
<td>Муниципаль программаны финанслау күләмнәре һәм чыганаклары</td>
<td>Җирле бюджет акчалары, бюджеттан тыш акчалар, республика бюджеты акчалары.
<table>
<tr><th>Финанслау чыганагы</th><th>2020 ел</th><th>2021 ел</th><th>2022 ел</th><th>2023 ел</th><th>2024 ел</th></tr>
<tr><td>Республика бюджеты</td><td>767,25</td><td>1280,5</td><td>1329,34</td><td>1 914,97</td><td>0,0</td></tr>
<tr><td>Җирле бюджет</td><td>64364,80</td><td>70702,8</td><td>87408,7</td><td>81264,7</td><td>81995,8</td></tr>
<tr><td>Бюджеттан тыш чыганаклар</td><td>3 400,00</td><td>3 400,00</td><td>3 546,5</td><td>3 000,0</td><td>3 200,0</td></tr>
<tr><td>Барлыгы</td><td>68532,05</td><td>75383,3</td><td>92284,54</td><td>86179,67</td><td>85195,8</td></tr>
</table>
Искәрмә: программаны финанслау күләме фаразлау характерына ия һәм тиешле елга тиешле дәрәҗәдәге бюджетларны формалаштыруны, шулай ук чараларны финанслашуга федераль һәм республика бюджетыннан акча бүлеп бирүне исәпкә алып, ел саен төзәтелергә тиеш.</td>
</tr>
</table>

## 1. МУНИЦИПАЛЬ ПРОГРАММАНЫҢ ПРОБЛЕМАЛАРЫ ҺӘМ МАКСАТЛАРЫ

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2008 елның 17 ноябрендәге 1662-р күрсәтмәсе белән расланган 2020 елга кадәрге чорга Россия Федерациясенең озак сроклы социаль-икътисадый үсеше Концепциясе нигезендә, спортны үстерү өлкәсендә дәүләт сәясәтенең төп юнәлеше булып, системалы үзгәртеп корулар аша кеше потенциалын үстерүне, социаль мохит сыйфатын һәм кешеләрнең тормыш шартларын яхшыртуны кертеп, халыкның тормыш сыйфатын күтәрү өчен шартлар тудыру тора.

Физик культура һәм спортны үстерү Арча муниципаль районының социаль-икътисади үсешенең бер өлеше. Әлеге тармактагы өстенлекле юнәлешләр-халыкның барлык яшь һәм социаль төркемнәрен даими рәвештә физик культура һәм спорт белән шөгыльләнүгә җәлеп итү өчен шартлар тудыру, республика, бөтенроссия һәм халыкара ярышларда район данын яклаучы югары квалификацияле спортчылар әзерләү өчен шартлар тудыру, физик һәм әхлакый яктан сәламәт яшь буын тәрбияләү. Физик культура һәм спорт район халкын сәламәтләндерүнең, балалар һәм яшьләрне гражданлык һәм патриотик рухта тәрбияләүнең мөһим чарасы булып тора.

Соңгы елларда Арча муниципаль районында физик культура һәм спортны үстерүдә уңай үзгәрешләр булды. Физик культура һәм спорт өлкәсенең матди базасын, кадрлар потенциалын үстерү, сәламәт яшәү рәвешен мәгълүмати яктан яклау буенча массакүләм мәгълүмат чаралары белән актив эшләү Арча районы халкын физик культура һәм спорт белән даими шөгыльләнүгә җәлеп итүгә ярдәм итте.

Спорт инфраструктурасын үстерү һәм эзлекле рәвештә камилләштерү өлкәсендә уңай үсеш күзәтелә. 2022 ел ахырына Арча муниципаль районы территориясендә 202 спорт объекты эшли:

асфальт җәелгән җиңел атлетика юлы булган 1500 урынга исәпләнгән 1 стадион

65 яссы корылма (50-волейбол һәм баскетбол мәйданчыгы, 15-футбол кыры)

2 бассейн

46 спорт залы

27 хоккей мәйданчыгы

1 ук ата торган тир

1 чаңгы базасы

1 «Арча - Арена» боз сарае
29 универсаль спорт мәйданчыклары
5 урам тренажеры
23 башка спорт корылмалары
1 ГТО нормаларын үтәү мәйданчыгы

Район территориясендә ике спорт мәктәбе эшли - «Арча» (1482 бала) һәм «Арча Арена» (224бала), анда 1706 укучы спорт белән шөгыльләнә.

Шәһәр һәм район халкы «Арча» спорт комплексында бассейнга, «Арча-Арена» боз сараена түләүле нигездә йөри ала.

Һәр ведомство карамагындагы учреждениедә түләүле хезмәтләр күрсәтүгә бәя прейскурантлары, шулай ук аз керемле һәм күп балалы гаиләләрдәге балаларга һәм яшүсмерләргә, ятим һәм опекага алынган, инвалидларга, сәламәтлекләре буенча мөмкинлекләре чикләнгән кешеләргә, КДН, ПДНда исәптә торучы балигъ булмаган балалар һәм үсмерләргә ташламалы һәм түләүсез нигездә әлеге хезмәтләр күрсәтү кагыйдәләре расланган.

Спорт юнәлешендәге өстәмә белем бирү муниципаль учреждениеләр (балалар-яшүсмерләр спорт мәктәпләре) һәм районның мәгариф учреждениеләре өчен спорт инвентаре сатып алу проблемасы кискен булып кала.

Әлеге системаны тотрыклы үстерү шартларын булдырырга программа чаралары ярдәм итә.

Шулай ук мәгълүмат белән тәэмин итүгә, сәламәт яшәү рәвеше алып бару өчен физик культура һәм спорт белән даими шөгыльләнүне актив пропагандалауга зур игътибар бирергә кирәк.

Арча муниципаль районында физик культура һәм спорт өлкәсендәге эш нәтиҗәләрен анализлап, муниципаль программаны гамәлгә ашыру, тулаем алганда, уңай күренешкә ия дип әйтергә була. Ул спорт корылмаларының матди-техник базасын ныгытырга, район халкын физик культура һәм спорт белән шөгыльләнүгә җәлеп итәргә мөмкинлек бирде. Хәзерге вакытта яңа муниципаль программаны эшләү һәм раслау зарурлыгы туды, анда 2020-2024 елларга Арча муниципаль районында физик культура һәм спорт өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыруның төп юнәлешләре чагылдырылырга тиеш.

Программаны куллану күрсәтелгән проблемаларны иң югары нәтиҗәле идарә иткәндә хәл итәргә мөмкинлек бирәчәк, бу алда торган проблемаларны хәл итүгә комплекслы якын килүне, шулай ук Программа чараларын гамәлгә ашыру нәтиҗәләрен планлаштыру һәм күзәтеп баруны тәэмин итәчәк. Программаны гамәлгә ашыру уңай тенденцияләрне ныгытырга, Арча муниципаль районында физик культура һәм спортны үстерү буенча максатчан эшне тәэмин итәргә мөмкинлек бирәчәк.

Физик культура һәм спорт өлкәсендә сәясәтнең төп стратегик өстенлеге булып сәламәт яшәү рәвеше кыйммәтләрен формалаштыру һәм үстерү тора. Шуңа бәйле рәвештә дәүләт һәм гражданинның көндәлек мөнәсәбәтләрендә үтә күренмәлелек, төгәллек һәм гадилеккә ирешергә кирәк. Бу мөнәсәбәтләрнең төп бурычы-кешеләрнең тормыш шартларын яхшырту. Хәзерге вакытта яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге эшчәнлегенең төп юнәлеше – яшьләр һәм өлкәннәрнең яшәү урыны буенча массакүләм физкультура хәрәкәтен киңәйтү.

Балаларны сәламәтләндерү лагерьларының матди базасын үстерү, ялны оештыру формаларын камилләштерү буенча эшне дәвам итәргә кирәк.

Киләсе елларга яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлегенең массакүләм һәм физкультура-сәламәтләндерү эшчәнлегенең төп максаты-Арча муниципаль районында халыкны физик культура белән даими шөгыльләнүгә җәлеп итү, сәламәт яшәү рәвешен пропагандалау.

Спорт юнәлешендәге объектларның нәтиҗәле эшләвен тәэмин итү мәсьәләләре безнең өчен тагын да актуальләшә бара. Шул ук вакытта, балалар, яшьләр һәм гаилә ялы өчен корылмаларның һәркем өчен ачык булуын тәэмин итеп, балалар спортына аерым игътибар бирергә кирәк.

Физик культура һәм спорт өлкәсен үстерүдә оештыру-икътисади механизмны камилләштерү буенча төп чаралар:

- төрле яштәге гражданнар өчен уку, хезмәт һәм ял режимына физик культура һәм спортны кертү;
- Татарстан Республикасы һәм Россия Федерациясенең төрле спорт төрләре буенча җыелма

командалары өчен спорт резервы, югары классллы спортчылар әзерләүне тәэмин итү;
- физкультура-сәламәтләндерү һәм массакүләм спорт чараларының календарь планнарын эшләү һәм гамәлгә ашыру;
- гореф-гадәтләрне, йолаларны һәм икътисади хәлне исәпкә алып, халыкның төрле категорияләре һәм төркемнәренең физкультура-спорт эшчәнлегенә ихтыяҗларын канәгатьләндерүне тәэмин итә торган шартлар булдыру;
- мәгариф учреждениеләрендә дәрестән тыш чаралар, шул исәптән спорт ярышлары һәм бәйрәмнәр оештыру һәм үткәрү, яшәү урыны буенча һәм ял паркларында физик культура һәм спорт белән шөгыльләнү өчен шартлар тудыру.
- ятим балалар, «авыр» яшүсмерләр, инвалидлар арасында физик культура һәм спортны үстерү программасын, шулай ук яшүсмерләр арасында наркоманлык, эчкечелек һәм башка тайпылышларны кисәтүгә юнәлдерелгән махсус программалар кабул итү һәм гамәлгә ашыру. Халыкның барлык яшь төркемнәре өчен (хезмәт коллективларында, яшәү һәм ял итү урыннары буенча, мәгариф учреждениеләрендә) массакүләм спорт төрләре буенча ярышлар санын арттыру.

Программаның төп максатлары:

1.Массакүләм физик культураны һәм спортны үстерү, халыкның сәламәтлеген ныгыту, Арча муниципаль районының спорт имиджын алга сөрү.

2. Физик культура һәм спорт белән шөгыльләнүдә халыкның агымдагы ихтыяҗларын канәгатьләндерү һәм яңа ихтыяҗларын формалаштыру.

3. Сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру.

4. Арча муниципаль районының барлык халкы өчен сәламәт яшәү рәвеше алып бару өчен шартлар тудыру

Әлеге максатларга ирешү өчен түбәндәге бурычларны хәл итү күздә тотыла:

1. Халыкта физик культура һәм спорт белән шөгыльләнүгә, сәламәт яшәү рәвеше күнекмәләренә карата тотрыклы кызыксыну формалаштыру;

2. Спортчылар әзерләүнең нәтиҗәле системасын булдыру, район спорт корылмаларының матди-техник базасын ныгыту һәм үстерү;

3. Арча муниципаль районы һәм Татарстан Республикасы спорт командалары резервын һәм югары классллы спортчыларны әзерләү өчен оптималь шартлар тудыру;

4.Халыкның төрле категория һәм төркемнәренә физик тәрбия бирү системасын модернизацияләү;

5. Арча районында яшәүчеләр өчен физик культура һәм спорт өлкәсе инфраструктурасын булдыру һәм үстерү;

6. Балалар һәм яшьләр өчен спортның төрле төрләре буенча календарь өйрәтү-спорт чараларын үткәрү өчен шартлар тудыру;

7. Яшәү урыны буенча спорт-сәламәтләндерү чараларын оештыру һәм уздыру өчен шартлар тәэмин итү;

8. Гомумшәһәр массакүләм спорт чараларын оештыру һәм уздыру өчен шартлар тәэмин итү;

9. Район халкының төрле категорияләре өчен массакүләм спорт-сәламәтләндерү чараларын оештыру һәм уздыру өчен шартлар тудыру;

10. Физик культураны һәм спортны сәламәт яшәү рәвешенең мөһим өлеше буларак пропагандалауны камилләштерү;

11. Яшьләр инфраструктурасын үстерү һәм тотрыклы эшләтү;

12. Физкультура-спорт эшчәнлеген оештыру-идарә итү, кадрлар, фәнни-методик тәэмин итүне үстерү.

## 2.МУНИЦИПАЛЬ ПРОГРАММАНЫ ГАМӘЛГӘ АШЫРУ СРОГЫ

Муниципаль программаны гамәлгә ашыру срогы - 2020-2024 еллар

## 3. МУНИЦИПАЛЬ ПРОГРАММАНЫ РЕСУРСЛАР БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮНЕ НИГЕЗЛӘҮ

Программа чараларын гамәлгә ашыру өчен җирле бюджет, бюджеттан тыш акчалар, республика бюджеты акчаларыннан файдалану күздә тотыла.

| Финанслау чыганагы | 2020 ел | 2021 ел | 2022 ел | 2023 ел | 2024 ел |
|---|---|---|---|---|---|
| **Республика бюджеты** | 767,25 | 1280,5 | 1329,34 | 1 914,97 | 0,0 |
| **Җирле бюджет** | 64364,80 | 70702,8 | 87408,7 | 81264,7 | 81995,8 |
| **Бюджеттан тыш чыганаклар** | 3 400,00 | 3 400,00 | 3 546,5 | 3 000,0 | 3 200,0 |
| **Барлыгы** | **68532,05** | **75383,3** | **92284,54** | **86 179,67** | **85195,8** |

Искәрмә: программаны финанслау күләме фаразлау характерына ия һәм тиешле елга тиешле дәрәҗәдәге бюджетларны формалаштыруны, шулай ук чараларны финанслашуга федераль һәм республика бюджетыннан акча бүлеп бирүне исәпкә алып, ел саен төзәтелергә тиеш.

## 4.МУНИЦИПАЛЬ ПРОГРАММА БЕЛӘН ИДАРӘ ИТҮ ҺӘМ АНЫ ГАМӘЛГӘ АШЫРУ МЕХАНИЗМЫ

Программада катнашучылар эшчәнлеген гамәлгә ашыру һәм координацияләү өчен җаваплы башкарма хакимият органы булып, тармак учреждениеләре, предприятие җитәкчеләре һәм башка оешмалар белән берлектә, Арча муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге тора:

- билгеләнгән тәртиптә Программа чаралары исемлеген, аларны гамәлгә ашыру чыгымнарын, шулай ук Программаны гамәлгә ашыру механизмын ачыклау буенча тәкъдимнәр әзерли;
- максатчан индикаторлар исемлеген һәм аларны квартал саен бүлүне төгәлләштерә;
- хисап кварталыннан соң килүче айның 15 числосына кадәр Программаны гамәлгә ашыруның барышы турында хисап әзерли һәм аны Арча муниципаль районы Башкарма комитетына тапшыра.

Хисап мәгълүматын җыю һәм агрегацияләү өчен Арча муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге җаваплы.

Программаны башкаручылар хисап кварталыннан соң килүче айның 10 числосына кадәр Программа чараларының үтәлеше турында мәгълүматны Арча муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлегенә тапшыралар.

## 5.МУНИЦИПАЛЬ ПРОГРАММАНЫҢ МАКСАТ КҮРСӘТКЕЧЛӘРЕ, ИКЪТИСАДИ, СОЦИАЛЬ ҺӘМ ЭКОЛОГИК НӘТИҖӘЛЕЛЕГЕН БӘЯЛӘҮ

Программаны гамәлгә ашыруның нәтиҗәлелеген бәяләү хисап елында Программа максатларына фактта ирешелгән күрсәткечләрне (индикаторларны) бәяләү һәм бурычларны хәл итү күрсәткечләре белән чагыштыру юлы белән үткәрелә.

Программаның иң мөһим социаль-икътисади нәтиҗәсе булып физик культура һәм спорт белән шөгыльләнүчеләр саны арту торачак, бу исә район халкының сәламәтлеген ныгытуга ярдәм итәчәк.

Балалар-яшүсмерләр спортын үстерү нәтиҗәсендә спортчыларның төрле дәрәҗәдәге

ярышларда уңышлы чыгыш ясарлык югары квалификацияле спортчыларның әзерлек дәрәҗәсе артачак, республика спартакиадасы исәбенә спортчылар саны күбрәк булачак.

Арча муниципаль районы халкының төрле категорияләрен физик культура һәм спорт белән шөгыльләнү процессына актив җәлеп итү наркомания, эчкечелек, тәмәке тарту һәм башка зарарлы гадәтләрнең кимүенә, авырулар санын киметүгә, эшкә сәләтлелекне арттыруга һәм район халкының гомер озынлыгын арттыруга ярдәм итәчәк.

Муниципаль программаның бюджет нәтиҗәлелеге физик культура һәм спорт өлкәсендә сәясәтне гамәлгә ашыру чараларына юнәлдерелгән чыгымнарның нәтиҗәлелеген арттырудан гыйбарәт.

Муниципаль программаны гамәлгә ашыруда экологик нәтиҗәлелек түбәндәгедән гыйбарәт:

- яшь буынны һәм яшьләрне әхлакый яктан тәрбияләүдә, шул исәптән әйләнә-тирә мохиткә сакчыл караштта;
- спорт мәйданчыклары өчен хуҗалык әйләнешендә катнашмаган җирләрдән файдалануда.

## 6. ПРОГРАММА ЧАРАЛАРЫ ИСЕМЛЕГЕ ҺӘМ ТАСВИРЛАМАСЫ

| № | Чаралар | Башкар учылар | Үтәү срогы | Финанслау чыганагы | Финанслау күләме (мең сум) | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 |
| 1. Физкультура-массакүләм эшне, халыкның хәрәкәт активлыгын үстерү | | | | | | | | | |
| 1.1 | Физкультура-сәламәтләндерү һәм спорт чараларының комплексы планнарын эшләү<br>- яшәү урыны буенча<br>- уку һәм хезмәт эшчәнлеге урыны буенча<br>- авыл халкы белән<br>- инвалидлар белән эшләү барышында<br>- иҗтимагый оешмалар һәм төрле юнәлештәге клублар белән<br>- спорт ветераннары белән | Яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге | 2020-2024 | Җирле бюджет | 2020 | 2021 | 2022 | 2023 | 2024 |
| 1.2 | Яшәү урыны буенча төрле яштәге халык катнашында физкультура-сәламәтләндерү һәм массакүләм спорт чаралары үткәрү | Яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге | 2020-2024 | Җирле бюджет | 98,00 | 198,0 | 973,04 | 68,0 | 68,0 |
| 1.3 | Предприятие хезмәткәрләре спартакиадасын оештыру һәм үткәрү | Яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге | Ел саен | Җирле бюджет | 150,00 | 250,0 | 100,0 | 100,0 | 100,0 |
| 1.4 | Физик мөмкинлекләре | Яшьләр | 2020- | Җирле | 73,00 | 73,00 | 73,00 | 73,00 | 73,00 |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | чикләнгән кешеләр арасында спорт эшен оештыру, җайлашкан физик культура һәм спортны үстерү өчен шартлар тудыру, өлкән яшьтәге кешеләрне сәламәтләндерү физкультурасына җәлеп итү | эшләре һәм спорт бүлеге Социаль яклау бүлеге | 2024 | бюджет | | | | | |
| 1.5 | Бөек татар шагыйре Г. Тукайның туган көненә багышланган "ТУКАЙ SKI – МАРАФОН" һәм Тукай марафонын оештыру һәм уздыру | Яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге | 2020-2024 | Җирле бюджет | 280,00 | 280,00 | 123,6 | 80,0 | 80,0 |
| 1.6 | Халык өчен физик культура һәм спорт белән шөгыльләнү мөмкинлеген тәэмин итү буенча шартлар тудыру | Яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге КДН "Мәгариф идарәсе" МУ ТР Эчке эшләр министрлыгының Арча районы буенча бүлеге | 2020-2024 | Җирле бюджет | 45.90 | 45.90 | 45.90 | 45,90 | 45,90 |
| 1.7 | Гомуми белем бирү учреждениеләре арасында физкультура-сәламәтләндерү һәм спорт эшен иң яхшы оештыруга смотр-конкурслар үткәрү | "Мәгариф идарәсе" МУ Яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге | 2020-2024 | Җирле бюджет | 60,00 | 60,00 | 50,0 | 50,0 | 50,0 |
| 2. Сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру, социаль тискәре күренешләрне профилактикалау | | | | | | | | | |
| 2.1 | Стационар һәм мәктәп яны лагерьларында физкультура - | Яшьләр эшләре һәм | 2020-2024 | Җирле бюджет | 65,00 | 65,00 | 45,0 | 45,0 | 45,0 |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | сәламәтләндерү һәм спорт чаралары үткәрү | спорт бүлеге "Мәгариф идарәсе" МУ | | | | | | |
| 2.2 | КДНда, ПДНда исәптә торучы балигъ булмаганнарны мәктәп коллективларының иҗади эшчәнлегенә җәлеп итү, төрле массакүләм мәдәни, спорт чараларында һәм секцияләрдә катнашу | Яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге КДН "Мәгариф идарәсе" МУ "Мәдәният идарәсе" МУ | 2020-2024 | Җирле бюджет | 37,00 | 37,00 | 37,00 | 37,0 | 37,0 |
| 2.3 | Тәмәке тартуны, эчкечелекне, наркоманияне профилактикалауга юнәлтелгән чараларны оештыру һәм уздыру | "АҮРХ" ДАССУ Яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге "Мәгариф идарәсе" МУ | 2020-2024 | Җирле бюджет | 80,00 | 80,00 | 80,00 | 80,00 | 80,00 |
| 3. Югары казанышлар спортын үстерү | | | | | | | | | |
| Ярышлар һәм конкурслар оештыру һәм үткәрүнең нәтиҗәле системасын булдыру | | | | | | | | | |
| 3.1 | Ел саен смотр-конкурслар оештыру һәм үткәрү:<br>- спортның олимпия төрләре буенча иң яхшы тренер һәм спортчы<br>- спортның олимпия булмаган төрләре буенча иң яхшы тренер һәм спортчы<br>- спортның уен төрләре буенча иң яхшы команда | Яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге | 2020-2024 | Җирле бюджет | 105,00 | 105,00 | 79,0 | 79,0 | 79,0 |
| 3.2 | Татарстан Республикасы | Яшьләр эшләре | 2020-2024 | Җирле бюджет | 525,00 | 697,3 | 1221,2 | 225,0 | 225,0 |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | чемпионатларында һәм беренчелекләрендә, турнирларында, бөтенроссия һәм халыкара ярышларда әйдәп баручы спортчыларның, районның җыелма һәм клуб командаларының катнашуы | һәм спорт бүлеге | | | | | | | |
| 3.3 | «Арча-Арена» спорт командаларының хоккей һәм (яки) Россия Федерациясе хоккей буенча чемпионаты буенча Татарстан Республикасы Чемпионатында катнашуы | Яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге | | Республика бюджеты | 379,50 | 359,9 | 890,3 | 1031,3 | - |
| 3.4. | Татарстан Республикасы спорт резервын әзерләүче физкультура спорт оешмаларын җиһазлау өчен спорт җиһазлары, экипировкалар һәм инвентарь сатып алу | Яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге | 2020-2024 | Республика бюджеты | 387,75 | 425,10 | 439,04 | 501,37 | - |
| 4. Яшьләргә гражданлык формалашуы, рухи-әхлакый тәрбия бирү өчен шартлар тудыру | | | | | | | | | |
| 4.1 | Яшьләргә хәрби-патриотик, рухи-әхлакый, экологик тәрбия бирү өлкәсендә район конкурслары, проектлары һәм программалар оештыру | Яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге Район хәрби комиссариат "Мәгариф идарәсе" МУ "Мәдәният идарәсе" МУ | 2020-2024 | Җирле бюджет | 75,00 | 75,00 | 55,0 | 55,0 | 55,0 |
| 4.2 | Ватан тарихының истәлекле даталарына бәйле чараларны оештыру һәм үткәрү | Яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге "Мәгар | 2020-2024 | Җирле бюджет | 70,00 | 70,00 | 70,00 | 70,00 | 70,00 |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | иф идарәсе " МУ "Мәдәният идарәсе " МУ | | | | | | | |
| 4.3 | Ел саен үткәрелә торган бәйрәмнәрдә (Яшьләр көне, Физкультурачылар көне, Шәһәр көне) | Яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге | 2020-2024 | Җирле бюджет | 207,60 | 307,6 | 495,96 | 157,6 | 157,6 |
| | БАРЛЫГЫ | | | | 2638,75 | 3128,8 | 4778,04 | 2698,17 | 1165,5 |
| | 5. Спорт өлкәсен матди тәэмин итү | | | | | | | | |
| 5.1 | МБУ "Арча" спорт мәктәбен, "Арча Арена" спорт мәктәбен матди тәэмин итү | | 2020-2024 | Җирле бюджет | 62493,30 | 68359,0 | 83960,0 | 80099,2 | 80830,3 |
| | | | | Республика бюджеты | 0,00 | 0,00 | 0,00 | | |
| | | | | бюджеттан тыш акчалар; | 3400,0 | 3400,0 | 3546,5 | 3000,0 | 3200,0 |
| 5.2 | Физик культура һәм спорт өлкәсендә муниципаль учреждениеләр тарафыннан муниципаль йөкләмәләрне үтәү максатларында, спорт объектларын террордан яклауны тәэмин итү өчен җиһазлар сатып алу | | 2020-2024 | Республика бюджеты | 0,0 | 495,5 | 0,0 | 0,0 | 0,0 |
| 5.3 | Дзюдо бүлеге ачылу уңаеннан Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының «Арча "спорт мәктәбе" муниципаль бюджет учреждениесе | | 2023 | Республика бюджеты | | | | 382,3 | |
| | **БАРЛЫГЫ** | | | | **65893,3** | **72254,5** | **87506,5** | **83481,5** | **84030,3** |
| | **БАРЛЫГЫ** | | | | **68532,05** | **75383,3** | **92284,54** | **86179,67** | **85195,8** |

Искәрмә: Программаны финанслау күләме фаразлау характерына ия һәм тиешле елга тиешле дәрәҗәдәге бюджетларны формалаштыруны, шулай ук чараларны финанслашуга федераль һәм республика бюджетыннан акча бүлеп бирүне исәпкә алып, ел саен төзәтелергә тиеш.